ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

“ 25 ” ноябрь 2016 ел № 1239

**2017 елга Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2017 елга Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга;

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2017 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2016 елның 29 сентябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары О.Е. Спичкинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

Арча муниципаль районы
"___" _________ 2016ел, №_____
карары белән расланды

**Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга НОРМАТИВ чыгымнар**

| гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә, елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 62007 |
| | авыл җирлеге | 63366 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 93220 |
| | авыл җирлеге | 96890 |